| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ**
**24.04.2017**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 182**

Зеленодольск муниципаль районында авыл халкының эшлекле активлыгын арттыру һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү чаралары турында мәгълүмат

Зеленодольск муниципаль районында авыл халкының эшлекле активлыгын арттыру һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү чаралары турында тыңлап фикер алышканнан соң, Зеленодольск муниципаль районы Советы Зеленодольск муниципаль районында (алга таба - район) кече хуҗалыкны, гаилә фермаларын, шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә юнәлдерелгән эш алып барыла, дип билгеләп үтә.

Районда авыл хуҗалыгы үсешен, халыкның хезмәт мәшгульлеген тәэмин итүче шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә, кече һәм урта бизнесны, гаилә фермаларын үстерүгә ярдәм итү дәүләт сәясәтен исәпкә алып, шулай ук Зеленодольск муниципаль районының алга таба нәтиҗәле социаль - икътисадый үсеше, алдагы елларга куелган бурычларны уңышлы тормышка ашыру максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. Зеленодольск муниципаль районында авыл халкының эшлекле активлыгын арттыру һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү турындагы мәгълүматны игътибарга алырга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына:

2.1. Зеленодольск муниципаль районында авыл халкының эшлекле активлыгын арттыру һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү буенча чаралар планын (алга таба - План) 2017 елның 15 маена кадәр эшләргә һәм расларга, һәм Зеленодольск муниципаль районы Советына җибәрергә;

2.2. Планның үтәлеше турындагы мәгълүматны Зеленодольск муниципаль районы Советына квартал саен җибәрергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы урынбасары Ф.Н. Шәмсиевка йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Советы рәисе** **А. В. Тыгин**